**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№523**
**07.02.2020**

«XXI гасыр лидеры» балалар һәм яшьләр иҗтимагый/ирекле берләшмәләре лидерлары һәм җитәкчеләре Бөтенроссия конкурсының шәһәр этабына әзерлек һәм аны үткәрү турында

Башкарма комитетның 2019 елның 30 октябрендәге 5596 номерлы карары белән расланган 2020-2022 елларга муниципаль яшьләр программасын үтәү йөзеннән, балалар һәм яшьләр мохитендә иҗтимагый эшчәнлекнең абруен күтәрү, коммерцияле булмаган оешмаларның, яшьләр һәм балалар иҗтимагый берләшмәләренең талантлы лидерларын һәм җитәкчеләрен ачыклау, бүләкләү һәм аларга ярдәм күрсәтү максатларында

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсенә 2020 елның 10 февраленнән 19 мартына кадәр Яр Чаллы шәһәрендә «XXI гасыр лидеры» балалар һәм яшьләр иҗтимагый/ирекле берләшмәләре лидерлары һәм җитәкчеләре Бөтенроссия конкурсының шәһәр этабын (алга таба – конкурс) оештыру һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

2. Расларга:

1) конкурс үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурска әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча;

3) конкурсның эксперт советы составын, 3 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә конкурска әзерлек һәм аны үткәрү чыгымнарын финанслауны 2020 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Яшьләр сәясәте» 07.07 бүлегендә (бүлекчәсендә) каралган акчалар хисабына 65 000,00 сум (алтмыш биш мең сум 00 тиен) күләмендә, 4 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2020 елның 7 февралендәге
523 номерлы карарына
1 нче кушымта

«XXI гасыр лидеры» балалар һәм яшьләр иҗтимагый/ирекле берләшмәләре лидерлары һәм җитәкчеләре Бөтенроссия конкурсының шәһәр этабын үткәрү турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «XXI гасыр лидеры» балалар һәм яшьләр иҗтимагый/ирекле берләшмәләре лидерлары һәм җитәкчеләре Бөтенроссия конкурсының шәһәр этабы (алга таба – конкурс) Яр Чаллы шәһәренең актив яшь гражданнарын ачыклау һәм бүләкләү, илне модернизацияләү, гражданлык җәмгыяте институтларын үстерү, мәдәниятара диалог процессына кушылган яшь гражданның позитив образын формалаштыру һәм популярлаштыру, шулай ук балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләренә булышлык итү һәм аларның уңышларын күрсәтүгә юнәлдерелгән. 2020 елда конкурс Татарстан Республикасында ТАССР төзелүнең 100 еллыгына һәм Россиядә Хәтер һәм дан елына багышланган.

2. Конкурс оештыруны һәм үткәрүне составы Башкарма комитет карары белән раслана торган конкурска әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты гамәлгә ашыра (алга таба – оештыру комитеты).

2 бүлек. Максатлары һәм бурычлары

3. Конкурсның максаты булып коммерцияле булмаган оешмаларның, яшьләр һәм балалар иҗтимагый/ирекле берләшмәләренең талантлы лидерларын һәм җитәкчеләрен ачыклау, бүләкләү, булышлык итү, балалар һәм яшьләр мохитендә иҗтимагый эшчәнлекнең абруен күтәрүдә ярдәм күрсәтү тора.

4. Бурычлары:

1) иҗтимагый хәрәкәт, яшьләр сәясәте, яшь гражданнарны тәрбияләүдә инновацион технологияләрне үстерү өчен шартлар тудыру;

2) балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләренең эшчәнлеген стимуллаштыру;

3) дәүләт яшьләр сәясәтенең төп юнәлешләрен популярлаштыру;

4) коммерцияле булмаган оешмаларның, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләр лидерларын һәм җитәкчеләрен дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыруда катнашуга җәлеп итү.

3 бүлек. Конкурста катнашучылар

5. Конкурста эшчәнлекләре Россия Федерациясе законнарына каршы килмәгән балалар һәм яшьләр иҗтимагый/ирекле берләшмәләре, коммерцияле булмаган оешмалар лидерлары һәм җитәкчеләре катнаша ала. Иҗтимагый берләшмәләр һәм ирекләләр отрядлары лидерлары һәм җитәкчеләре дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр булмаска тиеш.

6. Конкурс түбәндәге категория катнашучылар арасында үткәрелә:

1) иҗтимагый/ирекле берләшмә лидеры – катнашучы, иҗтимагый берләшмәнең төркем алдында торган бурычларны нәтиҗәле хәл итүче, башка катнашучыларның эш итүләренә әһәмиятле йогынты ясарга сәләтле вәкиле;

2) иҗтимагый/ирекле берләшмә җитәкчесе – оешманы гамәлгә куючы документлар нигезендә коллектив белән идарә итү функцияләрен гамәлгә ашыручы зат.

7. Иҗтимагый/ирекле берләшмәләрнең лидерлары һәм җитәкчеләренең иҗтимагый эш стажы яки аларны конкурска җибәргән берләшмә эшчәнлегендә катнашу тәҗрибәләре 1 (бер) елдан да ким булмаска тиеш.

8. Иҗтимагый/ирекле берләшмәләр эшчәнлеге Россия Федерациясе дәүләт яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә туры килергә тиеш.

9. Конкурсның номинацияләре:

1) балалар иҗтимагый/ирекле берләшмә активисты (11-13 яшь);

2) яшьләр иҗтимагый/ирекле берләшмә лидеры (14-15 яшь);

3) яшьләр иҗтимагый/ирекле берләшмә лидеры (16-17 яшь);

4) яшьләр иҗтимагый/ирекле берләшмә лидеры (18-30 яшь);

5) югары уку йорты/урта һөнәри уку йортының иҗтимагый/ирекле берләшмә лидеры (18-25 яшь);

6) балалар иҗтимагый/ирекле берләшмә җитәкчесе;

7) яшьләр иҗтимагый/ирекле берләшмә җитәкчесе.

10. Бер балалар яки яшьләр иҗтимагый/ирекле берләшмәсеннән катнашучылар саны чикләнмәгән.

## 4 бүлек. Үткәрү этаплары һәм сроклары

11. Конкурс этаплап үткәрелә:

I этап – читтән торып – 2020 елның 10 февраленнән 27 сенә кадәр;

II этап - урында – 2020 елның 28 февраленнән 1 мартына кадәр;

III этап - финал – 2020 елның 19 марты.

12. Конкурста катнашу өчен заявкалар 2020 елның 25 февралендә кертеп кабул ителә. Заявка конкурсның рәсми сайтында бирелә: www.lider-chelny.ru.

## 5 бүлек. Конкурсның программасы, бәяләү критерийлары

13. Конкурс үткәрү барлык этапларда да 3 баллы шкала буенча бәяләүне күздә тота:

1) конкурста катнашучы турыдан-туры катнаша торган иҗтимагый берләшмә эшчәнлегенең технологияләре һәм методикасы, инновацион алымнары;

2) катнашучының оештыру, иҗади һәм коммуникатив сәләтләре;

3) катнашучының идарә итү сәләтләре, осталыгы һәм күнекмәләре;

4) конкурсантның белем дәрәҗәсе: хокук белемнәре, иҗтимагый берләшмәләр эшчәнлегенә якын килү, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләренең төп юнәлешләре, принциплары, механизмнары;

5) мәгълүмати культура.

14. Конкурс өч этапны үз эченә ала: читтән торып, урында һәм финал. Урындагы һәм финалдагы этапларның баллары кушыла.

15. Конкурс программасының читтән торып үткәрелә торган этабы (2020 елның 28 февраленә кадәр) конкурсантның портфолиосын (папкасын) эксперт бәяләвен үз эченә ала, ул түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) «Белемнәр. Казанышлар. Тәҗрибә» катнашучының ирекле формада әзерләгән резюмесы (күләме машинкада басылган 1 биттән артмаган);

2) «Мин кемне лидер дип атыйм» темасына иҗади эссе (күләме машинкада басылган 1 биттән артмаган);

3) иҗтимагый берләшмәнең конкурсант турыдан-туры тормышка ашыруда катнашкан социаль проекты (проект бер елдан да ким булмаган вакытта тормышка ашырылырга һәм анда аны тормышка ашыру турында хисап булырга тиеш);

4) конкурсантның иҗтимагый эш тәҗрибәсен, аның уңышларын һәм казанышларын күрсәткән ирекле формадагы материаллар (фотоматериаллар, грамоталар, дипломнар һ. б.).

16. Урындагы этапта конкурс программасы катнашучыларның түбәндәге сынауларда эксперт бәяләвеннән гыйбарәт:

1) сәхнәдәге иҗади чыгышны күздә тоткан үз-үзеңне иҗади презентацияләү 3 минуттан да артмаска тиеш (чыгыш ясауның жанрын катнашучы үзе сайлый);

2) тәкъдим ителгән иҗтимагый берләшмә эшчәнлегенең төп юнәлешләре кысаларында эшләнгән проектны яклау. Регламент 3 минуттан да артык түгел.

17. Конкурсның финал этабы: форматы, тематикасы, эчтәлеген бирү оештыру комитеты тарафыннан өстәмә рәвештә раслана һәм бу хакта чараны үткәрүгә 2 көннән дә соңга калмый конкурста катнашучыларга хәбәр ителә.

18. Конкурста җиңүче дип эксперт советы бәяләве буенча үз номинациясендә иң күп балл җыйган катнашучы танылa. Баллар саны тигез булган очракта, җиңүчене билгеләгәндә, эксперт советы рәисе хәлиткеч тавышка ия була.

## 6 бүлек. Эксперт советы

19. Конкурсны үткәрү өчен составы Башкарма комитет карары белән раслана торган конкурсның эксперт советы төзелә.

20. Дәүләт хакимияте органнары, мәгариф, фәнни учреждениеләр, иҗат берлекләре һәм үзәкләре, мәдәният һәм фән, иҗтимагый берләшмәләрнең балалар һәм яшьләр белән эш оештыруда 1 (бер) елдан да ким булмаган тәҗрибәгә ия вәкилләре эксперт советы әгъзасы була ала.

21. Конкурсның эксперт советы:

1) конкурсны оештыру комитетына конкурсның конкурс программасы эчтәлеге, аны үткәрү тәртибе, конкурста катнашучыларның, шул исәптән һәр төркемдә катнашучыларның составы буенча тәкъдимнәр кертә;

2) конкурсантларның конкурс чараларында катнашуын бәяли;

3) җиңүчеләрнең һәм номинацияләрдәге призерларның исемлеген формалаштыра.

## 7 бүлек. Йомгак ясау

22. Конкурс сынауларында катнашуның йомгаклары буенча, әлеге Нигезләмәнең 9 пунктында күрсәтелгәнчә, җиңүчеләр һәм номинацияләрдә призерлар билгеләнә.

23. Һәр номинациядә 1 җиңүче, 2 призер билгеләнә.

24. Конкурста җиңүчеләр дипломнар һәм акчалата призлар белән бүләкләнә.

25. Конкурста җиңүчеләр «XXI гасыр лидеры» балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре лидерлары һәм җитәкчеләренең Республика конкурсында катнашуга тәкъдим ителәләр.

Башкарма комитетның
2020 елның 7 февралендәге
523 номерлы карарына
2 нче кушымта

«XXI гасыр лидеры» балалар һәм яшьләр иҗтимагый/ирекле берләшмәләре лидерлары һәм җитәкчеләре Бөтенроссия конкурсының шәһәр этабына әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты составы

| Т/с | Ф.И.А.и. | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1. | Хәлимов Рамил Мәрван улы | оештыру комитеты рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |
| 2. | Бахтина Зөлфия Васигъ кызы | «Орион» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе директоры |
| 3. | Засеева Вероника Кенесовна | оештыру комитеты рәисе урынбасары, Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгы урынбасары, яшьләр белән эшләү бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы |
| 4. | Сочнева Ольга Геннадьевна | шәһәр иҗтимагый оешмалар үзәге җитәкчесе (килешү буенча) |
| 5. | Хуҗин Рөстәм Нияз улы | Башкарма комитетның мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгы |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2020 елның 7 февралендәге
523 номерлы карарына
3 нче кушымта

«XXI гасыр лидеры» балалар һәм яшьләр иҗтимагый/ирекле берләшмәләре лидерлары һәм җитәкчеләре Бөтенроссия конкурсы шәһәр этабының эксперт советы
составы

| Т/с | Ф.И.А.и. | Вазыйфасы |
|---|---|---|
| 1. | Баукина Елена Юрьевна | «Диалог» психологик-педагогик ярдәм үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең психологик-педагогик ярдәм бүлеге мөдире |
| 2. | Климова Светлана Михайловна | «РИАТ» ҖЧҖ маркетологы (килешү буенча) |
| 3. | Мамаков Константин Павлович | «Орион» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе методисты, «Ирекле территория» региональ иҗтимагый оешмасы җитәкчесе |
| 4. | Сироткин Евгений Александрович | «Нур» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе директоры урынбасары |
| 5. | Ульдяков Дмитрий Юрьевич | «Яр Чаллы шәһәре предприятиеләре һәм оешмаларының яшьләр берлеге» яшьләр иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2020 елның 7 февралендәге
523 номерлы карарына
4 нче кушымта

«XXI гасыр лидеры» балалар һәм яшьләр иҗтимагый/иректе
берләшмәләре лидерлары һәм җитәкчеләре Бөтенроссия конкурсының
шәһәр этабын үткәрү чыгымнары
сметасы

| Т/с | Чаралар | Чыгымнар, сум |
|---|---|---|
| 1. | Акчалата призлар:<br>1 урын – 3000 сум. *5 номинация (Балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмаларының 11дән13 яшькә, 14 тән 15 яшькә, 16 дан 17 яшькә, 18 дән 30 яшькә кадәрге лидерлары, югары уку йорты/урта һөнәри уку йорты студент берләшмәләре лидерлары)<br>2 урын – 2000 сум. *5 номинация<br>3 урын – 1500 сум. *5 номинация<br>1 урын – 3500 сум. *2 номинация (Балалар иҗтимагый/иректе берләшмәсе җитәкчесе, яшьләр иҗтимагый/иректе берләшмәсе җитәкчесе)<br>2 урын – 2500 сум. *2 номинация<br>3 урын – 1500 сум. *2 номинация | 47 500,00 |
| 2. | Типография чыгымнары:<br>- Блокнот 38.00 сум. *90 данә<br>- Папка 40.00 сум. *80 данә<br>- Ручка 35.20 сум. *100 данә<br>- Бейдж 40.00 сум. *79 данә<br>- Диплом 15.00 сум. *80 данә<br>- Рамка 100.00 сум. *30 данә | 17 500,00 |
| барлыгы: | | 65 000,00 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова